РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«16 « декабрь, 2015 ел Олы Кайбыч ав. № 19

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставының 87, 88, 89 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2011 елның 26 апрелендәге 50 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәве узганнан соң, «Кайбыч таңнары» район газетасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 89 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, моңа «а, б, в» пунктларыннан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләрнең 1 өлешендәге, 2 өлешендәге, 7 өлешендәге нигезләмәләр керми.

5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр 1 өлештә, 2 өлештә, «а, б, в» пунктлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

**Совет Рәисе-**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Башлыгы** **А.И. Рәхмәтуллин**

Кайбыч муниципаль районы
Советының 2015 елның
16 декабрендәге 19 номерлы
кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр**

**1. “Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре 6 статьясының 1 өлешендә:**

а) 16 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

б) 17 пунктта «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 24.1 пункт өстәргә:

«24.1) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;»;

г) 31 пунктны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«31) муниципаль район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, муниципаль районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;».

**2. «Район составына керүче авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр» 6.1 статьясын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:**

«6.1 статья. Район составына керүче авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр

1) авыл җирлекләрендә яшәүче һәм аз керемле гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру, шулай ук органнарның башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

2) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

3) террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук авыл җирлекләре чикләрендә террорчылык һәм экстремизм чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу;

4) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү эшендә катнашу;

5) авыл җирлекләре китапханәләренең китапханәләр фондларын туплау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

6) авыл җирлекләре милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;

7) авыл җирлекләрендә традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

8) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан авыл җирлекләре урманнарыннан, махсус сакланылучы табигать территорияләрендәге урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, аларны торгызу;

9) авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, төзелешкә рөхсәт бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда объектлар файдалануга кертүгә рөхсәтләр раслау, авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм алу юлы белән, шул исәптән авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен сатып алу юлы белән, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, биналарны карап тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне карау һәм аларның барышын карау турында рекомендацияләрне бетерү;

10) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм авыл җирлекләре территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

11) авыл җирлекләре территориясендә һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм (яисә) авария-коткару формированиеләрен булдыру, тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

12) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

13) авыл җирлекләре территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны

тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

14) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, алардан файдалануның чикләүләре турында халыкка мәгълүмат җиткерү;

15) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

16) җирлекнең административ участогында эшләү өчен бина бирү, ул полициянең участок вәкаләтле вәкиле вазыйфасын биләүче хезмәткәргә;

17) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үтәү чорына торак урын бирү;

18) «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31.1 һәм 31.3 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

19) «Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;

20) авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру;

21) «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу.

**3. «Гражданнар сораштыруы» 19 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5.1 өлеш өстәргә:**

«5.1. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе район уставы яисә район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.».

**4. «Район Советы депутаты статусы» 26 статья:**

а) 4 пунктта «һәм район уставы» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт өстәргә:

«4.1. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре чоры муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм кимендә ике һәм биш ел була алмый.»;

в) 7 пунктның 4 пунктчасында «граждан» сүзләреннән соң «, административ» сүзен өстәргә.

**5. «Район Советы композициясе» 29 статья:**

а) 10 пунктта «муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру» сүзләрен «муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга; б) 19.2 пунктта «җирлекләрнең,» сүзләреннән соң «җирлекләрнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программалары,» сүзләрен өстәргә, җирлекләрнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программалары,» сүзләрен өстәргә.

**6. «Район башлыгы вәкаләтләре» 39 статьясындагы 2 пунктында түбәндәге сүзләр өстәргә:**

«хәлиткеч тавыш хокукы белән;».

**7. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 44 статьясының 3 өлешендәге 5 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша».

**8. «Район Советының хокукый актлары» 69 статья-сына түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш өстәргә:**

«2.1. Район башлыгының тавышы район Советы карарларын кабул иткәндә район Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»

**9. «Районда бюджет процессы” 79 статьясындагы 2 өлеше:** «аларны акчалата тотуга чыгымнарны» сүзләрен «аларның хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны» сүзләренә алмаштырырга.